*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

# ТЫЛСЫМ+

**Җиденче сан** **Март, 2016 нчы ел**

*Өченче республикакүләм «Фоат Садриев укулары»на багышланган махсус сан*

## Саннар ни сөйли?

**Фоат Садриев ул - прозаик, драматург, публицист**

*1981 нче ел - СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы*

*1991 нче ел - «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе»*

*1994 нче ел - «Таң җиле» романы өчен Әлмәт Язучылар берлегенең Р.Төхфәтуллин исемендәге әдәби бүләге иясе*

*1994 нче ел - «Шаһзаманов эше» китабы өчен Р.Фәхретдинов исемендәге премия иясе*

*2006 нчы ел - С.Сөләйманова исемендәге әдәби премия иясе*

*2010 нчы ел - “Бәхетсезләр бәхете” роман-трилогиясе өчен Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе*

*2010 нчы ел - Мөслим районының Мактаулы гражданины*

*2010 нчы ел - Мөслимдә Фоат Садриев исемендә яңа урам барлыкка килде*

*2014 нче ел - Халык язучысы исеме бирелде*

## ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

### Директор урынбасарлары семинары



4 нче мартта гимназия базасында Мөслим районы мәктәпләре директор урынбасарлары семинары булып узды. “Белем сыйфаттын күтәрүдә методик хезмәтнең роле” темасы астында уздырылган чарада мәгариф идарәсе методистлары һәм ветеран укытучылар да катнашты. Заманча белем бирү технологияләре кулланып оештырылган ачык дәресләр, мастер-класслар тәкъдим ителде. Катнашучылар “Түгәрәк өстәл” барышында Мөслим гимназиясенең методик эш оештыру тәҗрибәсе белән таныштылар.

### География буенча региональ олимпиада җиңүчеләре

Яр Чаллы шәһәре дәүләт педагогик технологияләр һәм ресурслар институтының тарих-география факультеты базасында география фәне буенча үткәрелгән региональ олимпиадада 9 нчы сыйныф укучылары Баев Шамил һәм Сәетгалиев Булат икенче, 8 нче сыйныф укучысы Фәхертдинова Айгөл өченче урын яуладылар. Укытучылары: Г.Н. Рәхимуллина.

### “Без яшь, без сәләтле...” интеллектуаль олимпиадасы призерлары

Фахруллин Булат һәм Шәйхиев Раил республикакүләм “Без яшь, без сәләтле...” интеллектуаль олимпиадасы призеры булдылар. Җиңүчеләрне һәм аларның сыйныф җитәкчеләре Р.С. Госсамова һәм А.Р. Гомәроваларны котлыйбыз.

### “Йолдызлык-2016” балалар эстрада сәнгате фестивале

Гимназия укучылары район, республиканың мәдәни тормышы үзәгендә кайныйлар. Март аенда “Йолдызлык - 2016” балалар иҗаты фестивалендә катнашу укучыларыбызга зур җиңүләр алып килде. Җитәкчеләре Г.Ф.Ямалова кул астында шөгыльләнүче Ләйсән Мәгъданова, Илнар Ямалов, Зәлия Баева, Илназ Яхин, Рәмис Вәлиев, Эльвина Хафизова “Конферанс” номинациясендә беренче урын яуладылар.



Музыка җитәкчесе Г.Ә.Фәхретдинова белән шөгыльләнүче сәләтле балаларыбыз арасыннан “Вокал-соло” номинациясендә 5 нче 6 сыйныфы укучылары Лиана Хәбибуллина беренче урын, Руслан Саламаев икенче, 10 нчы сыйныф укучысы Язиля Әһлиуллина өченче урынга лаек дип танылды. “Калфак” кызлар ансамбле “Вокаль ансамбль” номинациясендә беренче урын алды. Зур җиңүләрегез белән тәбрик итәбез сезне, дуслар!



### Спорт яңалыклары

XXVI кышкы спартакиаданың суперфинал ярышлары узды. Ай дәвамында барган ярышларда “Гимназия-Нептун” командасы, барлык сынауларны уңышлы үтеп, лаеклы рәвештә икенче урынга чыкты. Укытучы хезмәтен спорт белән бергә алып барган хезмәттәшләребезне уңышлы чыгышлары белән тәбрик итәбез. Җиңүләр дәвамлы булсын!

Гимназиянең укытучы-тренер Руслан Хантимеров җитәкчелегендәге 3-4 нче сыйныф укучыларыннан төзелгән җыелма командасы футбол буенча район ярышларында үз яшь категориясендә беренче урын яулады. Котлыйбыз!

Укучылар спартакиадасы кысаларында район администрациясе башлыгы призына кызлар арасында уздырылган мини-футбол уеннарында Д.Г.Шәйхетдинов җитәкчелегендәге команда беренче урынга лаек булды. Горурланабыз!

## ФОАТ АГА САДРИЕВКА — 75 ЯШЬ

### Һәр язганың йөрәк өстеннән үткән булырга тиеш.

*Фоат Садриев*



***Фоат ага! Гимназиядә ике ел рәттән ай саен чыгып килүче "ТЫЛСЫМ+" гәҗите белән сез таныштыр, дип уйлыйм. Сез үзегез дә вакытында район гәҗите редакторы булып эшләгәнсез. Мәктәп матбугаты булдыруга карата фикерегез ничек?***

Бик уңай карыйм. Элек, без үскәндә, һәр класста гәҗит чыгара идек. Мәктәпнең гомуми стенгазетасы була иде. Класс газетасының редакторы идем мин. Бәйрәм саен күмәкләшеп гәҗит чыгару бик рәхәт иде. Хәзер сезгә башка төрле мөмкинлекләр бик күп. Мәктәп гәҗите булдыру идеясен хуплыйм.

***Фоат ага! Сезнең һәр язган әсәрегез зур күпчелек тарафыннан яратып кабул ителә һәм иң күп укылучы китап буларак, "Ел китабы" конкурсында җиңүчеләр рәтендә йөри. Мондый уңышның сәбәбен нәрсә белән аңлата аласыз? Сәбәп сез яктырткан темаларның актуальлегендәме? Әллә заман укучысының зәвыгындамы?***

Мин моны тема актуальлегендә дә, укучы зәвыгында да күрмим. Яза торган әйберенә бик җитди карарга, ашыкмаска кирәк. Әгәр мин аны кичермәсәм, мин аны яза алмыйм. Бер битне язар өчен, минем бер атна вакытым китәргә мөмкин, ләкин ул чын булырга, һәр язганың йөрәк өстеннән үткән булырга тиеш. Мин әсәрне елап язам икән - укучы еларга тиеш, көләм икән - көлергә тиеш, сызланып язам икән - укучының да күңеле сызланырга тиеш. Минемчә, әдәби әсәрләрнең уңышы шунда.

***Фоат ага! Сез ялганга каршы көрәш тойгысы белән иҗат итәсез, гадел җәмгыять, дөреслек турында кискен фикерләр әйтәсез. Сезнең тормыш кредогыз нинди? Ә ул иҗат кредогыз белән тәңгәл киләме?***

Туры килә. Иң күрәлмаганым - ялган. Мин беркатлы кеше. Мине гомер буе алдадылар. Минемчә, дөньяның бар фаҗигасы ялганнан башлана. Ялганның нигезендә гел начарлык ята. Ә хакыйкать, дөреслек булганда, бар нәрсә ярылып ята. Ялган нәрсәнедер яшерә, кешенең аңын томалый ул.

***Фоат ага! Балалар өчен язу бик катлаулы эш дип беләм. Соңгы елларда кабат балалар өчен иҗат итә башлавыгызга нәрсә этәргеч булды?***

Хәзер балалар өчен иҗат итү эше белән бик актив шөгыльләнәм. "Тургай" атлы өч китаптан торган әсәр язам. Ул басыла башлады. Беренче өлешен "Казан утлары" журналының 2016 нчы елгы март санында күрергә була.

***Фоат ага! Өлкәннәр бүгенге яшьләрдән зарланырга ярата, ә сез заман яшьләрен яратам дип сөйлисез. Бу безгә ярaклашырга тырышудан гына түгелме?***

Хәзерге заман яшьләре бик үткен, бик белемле, максатчан. Араларында идеал итеп куярлыклары да бик күп. Мин мәктәпне тәмамлаган яшьләрне күзәтәм: әчүлек кимеде. Аларның омтылышлары бар, җыелып эшли, күңел ача беләләр. Тик мине бер нәрсә бик борчый: хәзерге кайбер яшьләргә җавапсызлык хас. Әлбәттә, бу зур күпчелеккә кагылмый, шулай да очрый. Тормыш авырлыкларын ата-ана үз җилкәсенә ала, балалар читтәрәк кала. Бәлки, бу аларга бар нәрсәнең җиңел бирелүе белән аңлатыладыр?..

***Соңгы арада бик тәэсирләнеп, "Рәхмәт, әтием!" әсәрен укыдым. Геройның әчке монологы – фәлсәфи монолог. Чыннан да, тетрәнерлек вакыйга нигез итеп алынган. Сюжетны каян алдыгыз? Геройларның прототиплары бармы?***

Бу геройларның прототиплары юк. Ләкин бер нәрсәне күзәтә килдем: кайчакта, кеше бер моментка бирелеп, үзе дә аңламаслык эшләр эшләп ташлый. Герой да шуның белән очраша. Кешелекне хаталардан саклап каласы иде!

**Блиц-сораулар:**

***Хыялыгыз:*** *язасы әсәрләрне язып бетерү*

***Язудан тыш яраткан шөгылегез:*** *бакча, агачлар, табигать*

***Кешеләрдә иң яхшы дип санаган сыйфат:*** *эчкерсезлек*

***Яраткан ризыгыгыз:*** *кабыклы бәрәңге*

***"Таң җиле" романын бөтен яшьтәге кешеләр дә яратып укый. Аны киләчәктә классик әсәрләр рәтендә санарлар дип исәплим. Барлык әсәрләрегезгә дә шундый язмыш телим. Кызыклы әңгәмәгез өчен рәхмәт!***

***Фоат Садриев белән 9 нчы а сыйныфы укучысы Илүзә Кашапова сөйләште.***

# ФОАТ САДРИЕВ ТУРЫНДА ЗАМАНДАШЛАРЫ

**Әдип вә галимнәре булмаган кавем бәхетсез, мәшһүр кемсәләрен оныткан халык көчсез, әдәбияты булмаган милләт рухсыз.**
***Ризаэтдин Фәхретдин***

**Айдар Хәлим:** Фоат Садриев – бүгенге көнебезнең иң бөек язучысы.

**Зөлфәт:** Фоат Садриев – татарның Шолоховы ул.

**Туфан Миңнуллин:** Бик шәп язучы Син, Фоат дус! Зур язучы! Оста, ләкин синең зурлыгыңны әдәби тәнкыйть бәяләп үк бетерми сыман.



**Дания Заһидуллина:** Тургай яз китерә, диләр халыкта. Теләсә кайсы милләтнең әдәбиятында «яз ясаган», үзгәрешләр китереп чыгарган язучылар бар. Фоат Садриев XX-XXI гасыр чиге татар әдәбиятында шундый каләм осталарының берсе.

Саф татарча матур, бай әдәби тел мөмкинлекләрен тулысынча файдалана белүче, милли әдәби традицияләрне яңа алымнар хисабына баетып килүче Фоат Садриев иҗаты әдәбиятыбызда тургай җыры булып яңгырый.

**Вахит Имамов:** Татар әдәбиятында, башкаладан читтә яшәп, Халык язучысы йөртүчеләр бик сирәк. Син - Мөслимнең солтаны.

**Гурий Тавлин:** «Таң җиле», минем фикеремчә, милли әдәбиятыбызда татар тормышын элекке эзләренә кайтаруны башлап җибәргән беренче карлыгачларыннан.

**Радик Фәизов:** Фоат Садриевнның “Таң җиле” романы – безнең соңгы еллардагы тормыш үзе. Анда әлеге тормышның бөтен югарылыклары һәм түбәнлекләре, барлык маҗаралары бар. Безнең заманга хас үзгәрешләр дә ярылып ята.



**Харис Әшрәфҗанов:** ...партия хакимияте дәрәҗәсендә булган мондый хәлләрне тирәнтен, көндәлек тормыштан чыгып фаш итү әле юк иде. Ф.Садриев әсәре шуның белән кыйммәтле, һәм ул авторның үсеш юлында икәнен күрсәтүче бер дәлил.

**Ринат Мөхәммәдиев:** Мөслимдә тын гына, ипле генә иҗат итеп яткан бер каләмдәшебез бар безнең – Фоат Садриев. Әмма аның кабатланмас прозаик һәм драматург булуын һәммәбез яхшы белсәк тә, еш искә алмыйбыз бугай үзен. Бу бишьеллык Фоат Садриев өчен аеруча бәрәкәтле булды. Аның “Таң җиле” романы бүгенге прозабызның иң гүзәл үрнәкләреннән.

**Рөстәм Мингалим:** Фоат Садриев Әлмәт театрының ышанычлы авторы булып калды.

**Факил Әмәк:** ...үзенең туган ягын, үзе белән бергә яшәгән якташларын әдәби биеклеккә күтәргән, ихлас зурлаган, кадерләп тасвир кылган башка язучы бармы бүген әдәбиятыбызда? Юктыр. Моның өчен бер генә шарт үтәлергә тиеш. Гомер буе үзе туып үскән якка – Мөслим төбәгенә тугры булып кала алган һәм туган ягында олуг Әдип, Шәхес булып житешкән Ф.Садриев булып туарга, яшәргә, иҗат итәргә кирәктер.

***Мәгълүматларны Язилә Исмәгыйлева туплады.***

## ТӨП БАСМА КИТАПЛАРЫ

**Ач тәрәзәң**: пьесалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986.

**Ике икең – ундүрт**: хикәяләр, әкиятләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1988.

**Шаһзаманов эше**: повесть, хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989.

**Тозлы бал**: драмалар, комедияләр, скетчлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1991.

**Таң җиле**: роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993.

**Таң җиле**: роман. – 2 басма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1994.

**Таң җиле**: роман/тәрҗ. Ә.Гәрәев, С.Шәрипов. – Өфө: Китап, 1994 (Башкорт телендә.)

**Адәм әүлиясе**: повестьлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1997.

**Бәхетсезләр бәхете**: роман. – 1 китап. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001.

**Көлми торган кеше**: повестьлар, хикәяләр, юморескалар. — Түбән Кама: «Ихлас» нәшрияты, 2004

**Бәхетсезләр бәхете**: роман. – 2 китап. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005.

**Безнең гомер язлары**: драмалар һәм комедияләр. — Казан: Рухият, 2005.

**Бәхетсезләр бәхете**: роман. – 3 китап. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007.

**Авылдан хатлар**: яшәешебезгә тәнкыйди бер караш.- Казан, 2009.

**Бәхетсезләр бәхете**: роман-трилогия. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2011.

**Таң җиле**: роман. — Казан: ШЭ Корбанов Р.Х., 2011

**Аппаккай**: балалар өчен хикәяләр, әкиятләр һәм сәхнә уеннар. — Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2013.



## ӘДӘБИ ТОРМЫШ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

### 2016 нчы елда Габдулла Тукай исемендәге Татарстан Дәүләт премиясе кемгә бирелер?

2016 нчы елда Габдулла Тукай исемендәге Татарстан Дәүләт премиясен дәгъвалаучылар исемлеге билгеле булды. Бу хакта республика Мәдәният министрлыгының рәсми сайты хәбәр итә. Татарстан Президенты каршындагы Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе комиссиясе тарафыннан расланган исемлектә якташыбыз Шәмсия Җиһангирова да бар. Ул 2011 нче елда Татар китап нәшриятында басылган «Илаһият: шигырьләр» җыентыгы һәм 2012 нче елда “Рухият” нәшриятында чыгарылган «Бәхетең үз кулыңда: җырлар» китабы белән югары бүләккә дәгъва итә.


### Иң күп укыла торган китаплар ачыкланды

Татарстан Республикасының Милли китапханәсе Мәдәният министрлыгы, Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы белән берлектә үткәрелә торган «Ел китабы–2014» конкурсына йомгак ясады. Конкурста 2014 нче елда басылып, 2015 нче ел дәвамында укылган 314 китап катнашты, дип хәбәр итә Милли китапханә сайты. Катнашкан басмаларның 39ы – чәчмә әсәрләр (проза), 54е – тезмә әсәрләр (шигърият), 43е – балалар әдәбияты, 43е – рус телендә чыккан матур әдәбият, 64е – татар телендәге публицистика һәм фәнни-популяр әдәбият, 71е – рус телендәге публицистика һәм фәнни-популяр әдәбият китаплары. Шунысы куанычлы: бу исемлектә безнең якташларыбызның китаплары иң күп укылучы китаплар рәтендә.

«Чәчмә әсәрләр» номинациясендә 1 нче урынга Роза Хәбибуллинаның «Мулла килене» китабы, «Балалар әдәбияты» номинациясендә 3 нче урынга Мөҗәһитнең «Баллы җәй» китабы чыкты. «Рус телендә чыккан матур әдәбият» номинациясендә 2 нче урында Факил Сафинның «Заблудившийся рассвет» (“Саташып аткан таң”) китабы булды. «Рус телендәге публицистика һәм фәнни-популяр әдәбият» номинациясендә 1 нче урынны Марсель Бакировның «Древнетюркская поэзия» хезмәте алса, Илдус Заһидуллинның «Татарское национальное движение в 1860–1905 гг.» китабы кызыксындыру бүләгенә лаек булды.

## “ФОАТ САДРИЕВ УКУЛАРЫ”ННАН ФОТОКҮРЕНЕШЛӘР





ТЫЛСЫМ+

Март, 2016 нчы ел

*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

**Баш мөхәррир:** Тимергалиева Э.В.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.
**Мөхәррир:** Исмәгыйлева Язилә
**Корректор:** Муллагалиева Алсу
**Корреспондентлар:** Мәгъдәнова Ләйсән, Фәхертдинова Айгөл, Кашапова Илүзә
**Дизайнер:** Галиев Илназ
**Компьютерда җыючылар:** Гилемов Азат, Хәбибуллин Руслан
**Гамәлгә куючы:** Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Электрон адрес:** tilsim.gimnazia@yandex.ru
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym